# XIX Гасыр Татар Теле Сүзлекләре

*XIXth Century Dictionaries of Tatar Language*

**Әлфия Юсупова**[*]

*Gazi Türkiyat, Bahar 2020/26: 23-44, DOI: 10.34189/gtd.26.002*

***Öz:*** *Çarlık Rusya'sı döneminde imparatorluğun ihtiyaçları doğrultusunda halkların özellikle de Rusya Müslümanlarının kültürüne ve diline olan ilgi giderek artmıştır. 19. yüzyıl, bu ilginin yoğun olduğu ve çeşitli üniversite ve okullarla vücut bulduğu dönemdir. Bu dönemde ve öncesinde bölgenin genel anlaşma dili olan Tatar dilinin söz varlığı da dil âlimlerinin dikkatini çekmiştir. Bu dikkatlerin politik, pedagojik olmak gibi farklı nedenleri vardır. Bu çalışmada da 19. yüzyılda doğrudan Tatarcanın söz varlığını barındıran sözlükler değerlendirilmiştir. İ. Giganov, A. Troyanskiy, S. Kuklyaşev, L. Z. Budagov, N. Ostroumov, K. Nasırî, Ş. Rehmetullin (Gebdelaziz), A. Voskresenskiy, E. Neklyudov, M. Yunusov gibi âlimlerin sözlükleri, sözlük birimlerin diziliş ve açıklanma yöntemleri, bölümleri, biçimleri, alıntı söz varlıkları, diyalektik söz yükleri, formatları gibi çeşitli yönleriyle ele alınmıştır. Ayrıca bu sözlüklerin yazılması ihtiyacını doğuran sebepler açıklanarak söz varlığı ve sözlüklerin yazılış maksatları arasındaki ilgiye dikkat çekilmiştir. Tatar sözlükçülüğünün ve sözlük biliminin temelini oluşturan bu sözlüklerin karşılaştırmalı olarak değerlendirilmesine imkân tanınmıştır.*

***Anahtar Kelimeler:*** *Tatarca, sözlük, sözlük bilim, leksikografi, tarihî sözlükler.*

***Abstract:*** *In the period of Tsarist Russia, the interest in the culture and language of the peoples, especially the Russian Muslims, gradually increased the needs of the empire accordingly. The 19th century is the period when this interest was intense and came into existence with various universities and schools. During this period and before, the vocabulary of Tatar language, which is the lingua franca of the region, also attracted the attention of philologists. There are different reasons for this attention, such as being political and pedagogical. In this study, dictionaries that directly contain the vocabulary of Tatar in the 19th century were evaluated. Dictionaries of scholars such as I. Giganov, A. Troyanskiy, S. Kuklyaşev, L. Z. Budagov, N. Ostroumov, K. Nasırî, Ş. Rehmetullin (Gebdelaziz), A. Voskresenskiy, E. Neklyudov, M. Yunusov, have been dealt with in various aspects such as the arrangement and explanation methods, sections, forms, citation vocabulary, dialectical verbals, formats of dictionary units. In addition, the reasons causing the need to write these dictionaries were explained, and attention was paid to the relation between the vocabulary and the dictionaries of the dictionaries. These dictionaries, which form the basis of Tatar lexicography and lexicography, have been given a comparative evaluation.*

***Keywords:*** *Tatar, Dictionary, Lexicography, Lexicography, Historical Dictionaries.*

XIX гасырда татар әдәби теле тарихында гаять күп яңарыш һәм үзгәрешләр була. Бу – телебез үсешендә бик бай, гаять үзенчәлекле, катлаулы чор. Телдәге үзгәрешләргә иҗтимагый мөнәсәбәтләр, милли күтәрелеш, җәмгыятьтәге тарихи вакыйгалар тәэсир итә. Әдәби телне халыкның җанлы сөйләм теленә якынайту һәм шул нигездә нормалаштыру мәсьәләсе куела. Яңа чор әдәби телнең

[*] *Prof. Dr., Kazan Federal Üniversitesi, Kazan/RUSYA. alyusupova@yandex.ru, https://orcid.org/0000-0003-4156-5705.* *Gönderim tarihi: 11.05.2020 / Kabul tarihi: 27.05.2020.*

эшкәртелүен, норматив грамматикаларның төзелүен, сүзлек хәзинәсен һәм тел байлыгын барлауны таләп итә.

XIX гасыр татар әдәби теленең иҗтимагый функцияләре киңәя, җанлы сөйләмгә нигезләнгән хәлдә, ул бөтенләй яңа юнәлештә үсә башлый. Гасырлар буе килгән тардицион язма тел сөйләм теле үзенчәлекләре белән тыгыз рәвештә кушыла бара (Хаков, 1993: 10-13).

Россиядә татар телен өйрәнүгә ихтыяҗ артканнан арта. 1803 елда Россия Фәннәр академиясендә гуманитар бүлек яңадан торгызыла. Мәскәү, Казан, Харьков университетларында көнчыгыш телләре кафедралары ачыла. 1812 елдан татар теле Казан университетының уку программасына кертелә һәм укытучы итеп Ибраһим Хәлфин билгеләнә. Шулай ук университетның татар - төрек телләре кафедрасында А.Казем-Бек, И.Н.Березин, М.Мәхмүтов эшли.

XIX гасырда төрле типтагы уку йортларында татар теле фән буларак укытыла башлый. Тобол, Томск, Оренбург, Саратов, Әстерхан, Ставрополь, Симферополь гимназияләрендә татар теле барлык милләт вәкилләренә дә өйрәтелә.

Патша Россиясенең көнчыгыш сәясәте татар телен белгән тәрҗемәчеләр, канцелярия хезмәткәрләре булуны таләп итә. Якын Көнчыгыш илләреннән килгән делегацияләрне Россия буйлап татарча белгән тәрҗемәчеләр озатып йөри. Оренбургтагы Неплюев кадет корпусы укытучысы М.Бекчурин, мәсәлән, шушы өлкәдәге тырыш хезмәте өчен патша Россиясенең югары бүләкләренә, орден-медальләргә лаек була.

XIX гасырда Россия территориясендә киң җәелгән миссионерлык хәрәкәте дә татар телен белүне таләп итә. Казан рухани академиясендә һәм семинариядә А.Троянский, Н.Ильминский, Е.Малов татар теленнән дәрес бирәләр, укыту тәҗрибәсенә таянып дәреслекләр, грамматикалар, сүзлекләр төзиләр.

Рус һәм татар халкы арасында үзара сәүдә-икътисади, иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни бәйләнешләрнең яшәп килүе дә һәр ике телгә ихтыяҗ тудыра. Шул сәбәпле ике тел байлыгын туплаган сүзлекләр дөнья күрә башлый.

Иң күп таралган сүзлекләрдән татарча-русча һәм русча-татарча сүзлекләрне күрсәтергә кирәк. Мондый сүзлекләрнең күпләп чыгуының төп сәбәпләре итеп түбәндәгеләрне күрсәтергә мөмкин: XVI гасырда рус дәүләте составына керү, рус әдәбияты һәм мәдәнияте белән якыннан танышу, руслар белән аралашу өчен уртак тел зарурлыгы, татар телен өйрәнеп, рус һәм татар халкы арасында сәүдә - икътисади бәйләнешләрне ныгыту, рус дәүләтенең җирле идарәләрендә эшләргә татарча белгән чиновниклар әзерләү, Россия тарихын өйрәнгәндә, татар телендә язылган тарихи чыганаклардан файдалана алу, самодержавиенең христианлаштыру сәясәтен уздырганда, татар телен белгән миссионерлар әзерләү

һ.б. Бу сәбәпләр XIX гасырда ике телле сүзлекләрнең барлыкка килүенә җирлек булып торалар.

Шулай итеп, бу чорда дөнья күргән сүзлекләр, нигездә, икетелле, ягъни татарча русча я русча-татарча сүзлекләр. Болай булуның сәбәпләре итеп, шул чордагы сәясәт, әдәби-мәдәни вәзгыять һәм Казан тюркология мәктәбенең бу юнәлештә зур эш алып баруын әйтергә кирәк. Бу вакыт аралыгында унөч тәрҗемәи, бер аңлатмалы, бер терминологик сүзлек дөнья күрә. Бу сүзлекләр галимнәр, укытучы-практиклар, дин эшлекләләре тарафыннан төзелә һәм алар барысы да бу хезмәтләрендә үзләренең эш практикаларын чагылдыралар.

И. Гигановның **«Слова коренные, нужнейшие к сведению для обучения татарскому языку, собранные в Тобольской главной школе учителем татарского языка И.Гигановым и Юртовскими муллами свидетельствованные»** (СПб, 1801. – 75 с.) сүзлеге авторның татар грамматикасына кушымта рәвешендә тәкъдим ителә. Сүзлектә урын алган 1800 лексик берәмлек төрле тематик төркемнәргә бүленеп бирелгән. Төркемнәрнең исемнәре рус телендә генә тәкъдим ителгән: «Область и его части с принадлежностями», «Дом и его части», «Разные вещи», «Конский прибор», «Вещи принадлежащие к одеянию», «Школа со школьными пособиями», «О стихиях и других естественных вещах», «О человеке, его возрастах и его частях», «О родстве», «О различных состояниях людей», «Месяцы с зодиакальными созвездиями», «О промыслах», «О животных», «О рыбах», «О деревьях и плодах», «О птицах», «О насекомых», «Об огородных растениях», «О луговой зелени» «О камнях и металлах», «Об именах встречающихся в других книгах», «О времени», «О добродетелях и пророках», «Имена означающие качества».

Сүзлектә сүзләрнең бирелеше бик гади. Башта гарәп графикасында татар сүзе, икенче баганада шул чорда кабул ителгән орфографик нормаларга буйсындырылып, сүзнең кирилл хәрефләре белән язылышы һәм өченче баганада – рус сүзе. Мәсәлән,

| | | |
|---|---|---|
| دروازه | *дарваза городскія* | ворота (с.1) |
| اوچ | *уцъ* | конецъ (с.2) |

Сүзлектә теркәлгән лексик берәмлекләрнең бер өлешен Себер татарлары, ягъни көнчыгыш диалект вәкилләре теленә генә хас булган сүзләр тәшкил итә. Теркәлгән сүзләрнең күбесе телебездә хәзер дә актив кулланыла, ләкин алар көнчыгыш диалектларга хас булган фонетик закончалыкларга буйсынган рәвештә бирелгәннәр. Алар арасында ашамлык атамаларын, тормыш – көнкүреш предметларын, табигать күренешләрен белдерә торган сүзләр бар. Мәсәлән, یاصدوغاچ*ястугачъ* (с. 7) колак мендәре, кечкенә мендәр дигәнне белдерә (Тумашева, 1992:72), سرة *сәртә* (с. 14) кыздырып, аш өстенә салынган май (Тумашева,1992:168) мәгънәсендә кулланыла.

И.Гигановнең 75 биттән торган сүзлеге - XIX гасыр башында дөнья күргән беренче ике телле сүзлек. Төзелеше ягыннан ул XVIII гасыр кулъязма сүзлекләренә һәм сөйләүлекләренә бик якын. Моңа төп дәлил итеп сүзлекнең тематик принципта төзелүен һәм хезмәттә телдә иң актив кулланылышта булган берәмлекләрнең генә теркәлүен күрсәтергә була.

Гомумән алганда, И. Гигановның тел белеме өлкәсендәге хезмәтләре үз вакытында татар телен өйрәнү өчен гаять файдалы кулланмалар булып саналган. Алар төрки телләрне өйрәнүдә мөһим урын билиләр. Хәзерге вакытта исә, әлеге хезмәтләр шул чор теленең лексик составын өйрәнү, бигрәк тә, көнчыгыш диалектларны тикшерү өчен бай чыганак булып торалар.

И.Гигановның икенче сүзлеге «**Словарь российско-татарский, собранный Тобольском главном народном училище учителем татарского языка И.Гигановым и муллами Юртовскими**» дип атала. Ул 1804 нче елда Санкт-Петербургта басылган. Сүзлек 672 биттән гыйбарәт. Рус сүзләренә сүзгә-сүз җыйнак һәм аңлаешлы тәрҗемә бирелгән. Сүзлекнең төзелеше безнең заманда камилләшкән сүзлек төзү принципларына якын тора. Сүзләр рус алфавиты тәртибендә урнаштырылып, күп очракта бу тәртип сүзнең беренче хәрефенә генә түгел, аннан соң килгәннәренә дә карый. Сүзлекнең һәр битендә сүзләр өч графага бүленгәннәр. Беренчесендә алфавит тәртибен саклап рус сүзе бирелә; икенчесендә, әйтелеш дөреслеген сакларга тырышып, рус хәрефләре белән сүзнең татарча укылышы язылә; өченче графада гарәп графикасында татар сүзе бирелә:

| | | |
|---|---|---|
| Аллебарда | *айбалта* | ائبالطا (с.3) |
| Алтынъ | *учъ теиньликъ* | اوچ تينلک (с.3) |
| Аптека | *дару ханясъ* | داروخاناسی (с.4) |

Ныклы алфавит тәртибе авторның сүзлек төзү принциплары белән якыннан таныш булуы турында сөйли. Ул сүзлек белән кулланучылар өчен дә билгеле бер уңайлылык бирә. Кайбер очракта бирелгән сүздән соң бер тамырдан ясалган, яисә мәгънәдәш сүзләр күрсәтелә. Бу вакытта алфавит тәртибе бозыла. Мондый алым сүзлек белән эшләүне җиңеләйтә һәм татар теле лексикасын тиз истә калдыруда зур роль уйный.

«Словарь Российско-татарский» хезмәтендәге лексик байлыкның төп өлешен шул чор татар халык сөйләм һәм язма теленә хас булган, шулай ук Себер татарлары сөйләмендә кулланыла торган сүзләр тәшкил итә. Шулардан бер өлеш хәзерге татар әдәби теленең һәм көнчыгыш диалектының сүзлек фондына керәләр.

И.Гиганов сүзлекләре лексик берәмлекләрнең күләме ягыннан, структур яктан бер берсеннән аерылып торалар. Беренче сүзлек телне башлап өйрәнүчеләр өчен төзелгән булса, икенче сүзлек академик басма рәвешендә

эшләнгән. Тагын шуны да ассызыкларга кирәк, И.Гигановның сүзлекләре диалектологик сүзлекләрнең башлангычы булып саналалар. Соңрак алар үрнәгендә татар теленең яңа диалектологик сүзлекләре дөнья күргән.

Гомумән алганда, И. Гигановның тел белеме өлкәсендәге хезмәтләре үз вакытында татар телен өйрәнү өчен гаять файдалы кулланмалар булып саналган. Алар төрки телләрне өйрәнүдә мөһим урын билиләр. Хәзерге вакытта исә, әлеге хезмәтләр шул чор теленең лексик составын өйрәнү, бигрәк тә, көнчыгыш диалектларны тикшерү өчен бай чыганак булып торалар.

А.Троянскийның татар лексикографиясенә керткән өлеше бик зур, ләкин бүгенге көнгә кадәр галимнең гаять күләмле сүзлеге тиешенчә тикшерелмәгән һәм үзенә лаеклы бәяне алмаган. Хезмәтнең исеме —**«Словарь татарского языка и некоторыхъ употребительныхъ въ немъ реченiй арабскихъ и персидскихъ, собранный трудами и тщанiемъ учителя татарского языка въ Казанской семинарiи священника Александра Троянского и напечатанный съ дозволенiя комиссiи духовныхъ училищъ»**. Беренче томы 1833 елда Казан университеты типографиясендә басылып чыга. Ул 629 биттән тора, анда якынча 6490 сүз теркәлгән. Ә икенче томы 1835 елда басыла, ул 340 биттән гыйбарәт. Бу томда якынча 3400 сүз бар. Сүзлекнең форматы – 26*25.

Сүзлекне бастыруга рөхсәт 1829 елның 31 декабрендә бирелә. Беренче биттә мондый юллар бар: «По журналу Комиссiи Духовныхъ училищъ 31- го декабря 1829 года состоявшемуся, печатать дозволяется для употребленiя въ подведомственныхъ оной Комиссiи учебныхъ заведенiяхъ. Казанской Семинарiй Ректоръ, Архимандритъ и Кавалеръ Өеофанъ»

Сүзлекнең төзелешенә, структурасына килгәндә, бу - алфавит тәртибендә төзелгән татарча – русча сүзлек. Сүзләрнең фонетик вариантлары аерым лексик берәмлек буларак теркәлгәннәр.

| | |
|---|---|
| اتچ | Пѣтухъ, пѣтелъ, кочатъ (т.1, с.6) |
| اتش | Огонь, (пер. сл.) (т.1, с.6) |
| وله ن | Трава, мурава, зелень (т.1, с.131 ), |
| اوي | Дом, изба, покой (т.1, с.139), |
| اويرمه | Вихарь, буря, сильный ветер (т.1,с.139) |
| ايسلي | Душистый, вонючий, угарный, или: имеющий запах, дух, вонь, угар ( с.153). |

Географик атамаларны, милләт атамаларын теркәү сүзлекне тагын да кызыклырак итә. Бу атамалар укучының дөньяга карашын киңәйтә, аның белемен арттыра. Хәзерге телдә бары рус варианты гына кулланылган географик атамаларның гарәп-фарсы, төрки вариантлары теркәлү сүзлекнең кыйммәтен тагын да арттыра.

А.Троянскийның татарча – русча сүзлеге башка милләт вәкилләрен татар теленә өйрәтү максатын күздә тотып төзелгән. Бу татар сүзләрен рус теленә тәрҗемә итүдә ачык чагыла. Татарча бирелгән һәр сүзнең рус телендәге тәрҗемәсе, тәрҗемәнең барлык синонимнары, вариантлары күрсәтелә.

Автор сүзләрне килеп чыгышына да игътибар итә һәм һәр сүзнең кайсы телдән керүен күрсәтеп бара. Мәсәлән, сүзләр янында «арас.», «перс» дигән искәрмәләр бар. Мисал өчен, پیشه *пишә* (перс.) – рукоделье, художество (с.259), تحسين*тәхсин*[1] (арас.) – хвала, похвала, одобрение (с.281), تفراج*тәфәрреҗ* (арас.) – веселье, забава, утешение, восхищение, увеселение (с.331), تفرق тәфәррык (арас.) – развод, разведение, разлука, отдел, отделение (с.331), چشم *чишм* (перс.) – глаз (с.467), اته ش *атәш* ( перс.) – огонь (с.9), جفت *җефет* (арас.) - жена, супруга (с.401). Автор татар телендә пассив булган, сирәк кулланылган алынмаларны гына аерып күрсәтә. Шул рәвешле, беренче томда - 374 гарәп, 162 фарсы сүзе, икенче томда 283 гарәп, 23 фарсы сүзе бирелә. Ләкин сүзлектә теркәлгән гарәп-фарсы алынмалары моның белән генә чикләнми.

Автор кайбер сүзләр янына җәяләр эчендә «трава», «дерево», «платье», «плод», «зверек», «растение», «рыба», «болезень», «грамматический термин» дип, сүзләрнең лексик мәгънәсен ачып бара, кайсы тематик төркемгә мөнәсәбәтле булуларын күрсәтеп үтә. Ләкин бу искәрмәләр һәрвакытта да куелмый. Автор укучы өчен бик үк таныш булмаган, пассиврак кулланылган сүзләрне шулай билгеләгәндер дип гөман кылырга мөмкин.

Сүзлектә фигыльләр -мак формасында теркәлгәннәр. Төрле юнәлешләрдәге фигыльләр аерым берәмлек итеп күрсәтелгәннәр. Берничә мисал китереп үтик: جرطماق*җыртмак* – драть, раздирать, разодрать, изодрать, рвать, разорвать, изорвать (с.393); جرطدرماق *җыртдырмак* – велеть драть, раздирать, изодрать, рвать, разрывать, разорвать, изорвать (с.393); جرطشماق *җыртышмак* – взаимно с кем драть, раздирать, издирать (с.393); جرطلماق *җыртылмак* - драться, раздираться, изодраться, рваться, разрываться, разорваться, изорваться, или быть раздираему, издираему, разрываему (с.394).

Сүзлек турында гомуми нәтиҗә ясап әйткәндә, А.Троянский сүзлеге — XIX гасырның беренче яртысында дөнья күргән иң зур татарча-русча сүзлек булуын искәртү зарур. Ул алда каралган И.Гиганов сүзлекләреннән лексик берәмлекләрнең составы, байлыгы ягынна аерылып тора. Анда 22 меңнән артык сүз һәм сүз формасы тупланган. Сүзләр тормышның торле өлкәләренә карый һәм һәр сүзнең синонимнары, диалекталь вариантлары аерым сүзлек мәкаләсе итеп

[1] А.Троянский сүзлегендә гарәп алынмалары диокритик билгеләр белән тәкъдим ителә. Техник сәбәпләр аркасында бу билгеләр текста күрсәтелми.

формалаштырылган. Бу искиткеч зур лексик байлык аерым монографик өйрәнүгә лаек.

С.Кукляшевның **«Словарь къ татарской хрестоматии»** хезмәте 1859 елда Казан университеты типографиясендә басылып чыга. Сүзлекне бастырып чыгарырга цензор И.Готвальд рөхсәт бирә. Титул битендә «Печать дозваляется съ темъ, чтобы по напечатаніи представлено было въ цензурный Комитетъ указанное число экземпляровъ. Казань, 19 мая 1859 г. » дип язылган. Хәзерге вакытта сүзлекнең берничә нөсхәсе Казан дәүләт университеты китапханәсенең сирәк китаплар бүлегендә Готвальд фондында саклана.

С.Кукляшевның хрестоматиясе һәм аңа кушымта итеп төзелгән сүзлеге, иң беренче чиратта, татар булмаган укучыларга адресланган. Сүзлекнең максаты — хрестоматиядә урын алган һәр сүзгә, ягъни 3546 лексик берәмлеккә русча аңлатма бирү, аңлату, тәрҗемә итү.

Сүзлек алфавит тәртибендә төзелгән: башта гарәп шрифты белән язылган татар сүзләре теркәлгән һәм каршысында русча тәрҗемәсе дә бирелгән. С.Кукляшев сүзләргә аңлатмаларны, контекстка нисбәтле рәвештә, мөмкин кадәр тулырак бирергә омтыла:

*а.* امر *әмер* – приказаніе (с.14)
بالچق *балчык* – грязь, глина (с.23)
*а.* امان *аман* – безопасность, миръ, пощада, покой (с.14)
ومچ *умач* – мучной бульонъ (с.19)
دلدل *дөлдел* – конь Алія, 4 арабскаго халифа (с.49)
Сүзлекнең форматы – 16*22.

Шунысы мөһим: С. Кукляшев, А.Троянский үрнәгендә, шартлы билгеләр ярдәмендә гарәп, фарсы, кыргыз (казах), иске татар һәм төрек сүзләрен дә билгеләп бара (а. – значить арабския слова, п. – персид, к. – киргизския, т. – турецкая или старотатарские слова, вышедшые из употребления, с. – значитъ слово составленныя из арабских или персидских слов с прибавлением на конце оных татарскихъ частицъ или глаголов). Әгәр дә башка сүзлекләрдә татарча сүзләр я хәрәкәләр, я янәшәдә рус хәрефләре белән бирелгән булса, бу сүзлектә исә андый хәл күзәтелми. Шуның нәтиҗәсендә, аерым сүзләрне уку авырая, аларны төрлечә уку ихтималлыгы туа.

Сүзлек бик үзенчәлекле. Бу хезмәттә С.Кукляшев хрестоматиясендә урын алган текстлардагы лексик берәмлекләр сүзлек формасына китереп, тәрҗемә ителгән. Монда телдә актив кулланылышта булган сүзләрне дә, шулай ук кулланылышы чикле, пассив булган берәмлекләрне дә күрергә мөмкин.

Хрестоматиядәге төрки - татар телендә язылган үрнәкләр дә бар. Ләкин, нигездә, текстлар гарәп, фарсы теленнән тәрҗемә ителгән һәм шуңа күрә сүзлектә гарәп һәм фарсы сүзләре аеруча күп.

Сүзлек, иң беренче чиратта, рус яки башка милләт вәкиле өчен төзелгән, шуңа күрә сүзләрне тәрҗемә итү алымнары бигрәк тә игътибарга лаек дип уйлыйбыз. Сүзгә сүз, ягъни эквивалент тәрҗемә сүзлектә төп урынны алып тора: امر *әмер* – приказание (с.14), بوري *бүре* – волкъ (с.26), بلبل *былбыл* – соловей (с.26). Ләкин автор сүзнең бер тәрҗемәсе белән генә чикләнеп калмый, булган синонимнарны да теркәп бара. Мәсәлән: ايمام *имам* – имам, мулла, священник (с.14), امان *аман* – безопасность, мир, пощада, покой (с.14 ), انط *ант* – присяга, клятва (14 с.) . Бу алым бер телдәге сүзнең мәгънәсен икенче тел вәкиле өчен тулырак, төгәлрәк аңлату мөмкинлеген ача.

Кайбер сүзләргә автор аңлатмалар, иллюстрацияләр бирә. Бу сүзләр — я халык атамасы, я дини термин, я милли үзенчәлеккә ия берәмлек. Мәсәлән, ومچ *умач* – мучной бульон (с.19 ), دلدل *дөлдел* – конь Алия, 4 арабского халифа (49 с.), صور بازاري *сур* базары – базаръ, торгъ сурками в мае месяце при г. Оренбурге (с.62).

С.Кукляшев сүзлеген бу чорда дөнья күргән сүзлекләрдән үзенең эчтәлеге белән аерыла. Сүзлекнең төзелү максаты да төгәл билгеләнгән. Ул хрестоматиягә кушымта итеп төзелгән, шуңа күрә сүзләр составы бик үзенчәлекле. Сүзлектә хрестоматиялә урын алган хикәяләрдәге сүзләр генә теркәлгән һәм шул сүзләргә аңлатма бирелгән.

Сүзлек, бер яктан, текстларны аңларга, төшенергә мөмкинлек бирсә, икенче яктан, тел һәм лексикография тарихын өйрәнүдә мөһим чыганак булып тора. Кызганычка каршы, практикада һәм лингвистик тикшеренүләрдә бу сүзлек әле бөтенләй диярлек искә алынмый.

XIX гасырның икенче яртысында дөнья күргән ике телле сүзлекләр арасында Л.З.Будагов сүзлеге – аеруча кызыклы хезмәт. Башка сүзлекләрдән ул үзенең үзенчәлекле сүзләр җыелмасы, татар сүзләре белән бергәттән төрек сүзләренең күп булуы, А.Нәваи, Бабур, Абу-л-Гази әсәрләренә, төрки телләрнең шәрык сүзлекләренә (аңлатмалы, тәрҗемә), төрки-европа сүзлекләренә, төрки-фольклор язмаларына нигезләнүе белән аерыла.

Л.З. Будаговның гыйльми хезмәтләре арасында заман сынауларына бирешмәгән, төрки лексикография тарихында тирән эз калдырган «**Сравнительный словарь турецко-татарскихъ наречій, съ включеніемъ употребительнейшихъ словъ арабскихъ и персидскихъ и съ переводомъ на русскій языкъ составилъ ЛАЗАРЬ БУДАГОВЪ доцентъ восточного факультета С.-П.Университета и драгоманъ V – го класса при Азіятском департаменте**» («Төрек-татар телләренең чагыштырмалы сүзлеге... ») - тел белеме өлкәсендә аеруча әһәмиятле. Бу хезмәт әлегә кадәр фәнни әйләнешкә

кермәгән, гаять кызыклы лексикологик материал туплаган булуга карамастан, аның турында мәкаләләр, монографияләр язылмаган.

Бу сүзлекне Л.Будагов бик озак төзи. 1864 елның 8 январенда факультет укытучыларына ул сүзлекнең структурасын, сүзләр составын аңлата. Төрки телләрдән сүзлеккә казан, кыргыз (казах), тобол, башкорт, чагатай, төрек, кырым, ногай, әзербайҗан телләре сүзләре керү турында әйтә.

Сүзләрнең урнашу тәртибе казан татарларында кулланыла торган алфавит тәртибендә булуын ассызыклый, чөнки автор бу алфавитны гамәли яктан иң алга киткән әлифба дип саный (Усманов, 1980: С.101-102).

Сүзлек 1869 -71 елда дөнья күрә. Ул Мәскәү шәһәре, Армән тыкрыгы, 2 йортта урнашкан Фәннәр Академиясенең Азия халыклары институтының көнчыгыш әдәбияты нәшриятында әзерләнә, Санкт Петербург император Фәннәр Академиясе типографиясендә басылып чыга. Тиражы зур түгел – бары 1500 данә. Күләменә килгәндә, бу сүзлек - XIX гасырда чыккан иң зур сүзлекләрнең берсе: 1 - нче том - 800 биттән тора, 17*26 форматлы, 2 - нче том 415 биттән тора. Ике томда барлыгы 25200 лексик берәмлек теркәлгән. Сүзлекнең титул битендә автор үзе турында да мәгълүмат биреп үтә. Ул үзен Санкт - Петербург университеты доценты, Азия департаментының бишенче класс драгоманы дип күрсәтә. Титул битендә автор турында шундый белешмә бирү XIX гасырда шактый киң таралган күренеш була.

Сүзлекнең күләме һәм лексик составы ике төрки тел материалына – татар һәм төрки телләргә нигезләнгән булуы белән билгеләнә.

Сүзлектә шулай ук гомумтөрки һәм арадаш лексика да урын алган. Бу бигрәк тә барлык төрки телләр өчен уртак булган берәмлекләргә багышланган сүзлек мәкаләләрендә чагылыш таба. Мәсәлән: *bas* 'голова' (с. 225-228); *ajaq* 'нога' (с.174-175); *ajmaq* «сказать, говорить' (с.178-179). Л.Будагов диалекталь һәм гади сөйләм сүзләрен дә сүзлектә шактый күп теркәгән һәм бу сүзләргә багышланган «провинц.» или «простом.» дигән билгеләр куйган. Мәсәлән: «тур. *bisrak.* (провинц.) - одногорбый верблюд» (с. 258); «тур. *bobrek, bogrek* (простон.) *bowrek* почка» (с. 272), «тат. *mant* пчельник (у приволжских татар селения Тархан; у других татар это слово неизвестно)» (с. 673). Кайбер очракларда «хатын-кыз теле»берәмлекләре дип, төрки телләрдә кулланыла торган аерым сүзләр теркәлгән. Мәсәлән: «кир. *kobogen* детки, ребятушки (старушечье слово)» (с. 142); man*ya cirik* «бранное выражение кумыкских женщин» (с. 198).

Сүзләргә аңлатма биргәндә, Л. Будагов эзлекле рәвештә «Wort und Sache» дип аталган методикага нигезләнә, ягъни сүзләрне аңлатканда сүз белдергән предмет һәм төшенчә турында мәгълүмат бирә. Шуңа нисбәтле рәвештә, Л.Будагов сүзлеге төрки халыкларның иҗтимагый-сәяси, мәдәни тормышын, көнкүрешен чагылдырган энциклопедиягә әйләнә.

Сүзлекнең кереш сүзендә автор әлеге хезмәтнең максатын аңлатып үтә. Сүзлекнең укучыларга, чиновникларга, сәүдәгәрләргә адреслануын һәм шуңа күрә бары тик иң актив сүзләрне генә туплавын искәртә.

Сүзлекнең күләме һәм сүзләр составы ике төрки тел материалын чагыштырып бирү белән дә бәйле. Сүзлектә гомумтөрки сүзләр зур урын алып торалар. Бу төркемгә караган берәмлекләрнең сүзлек мәкаләләре шактый күләмле итеп эшләнгән.

Сүзлектә диалекталь һәм гади сөйләм сүзләре дә шактый теркәлгән, алар янына автор «провинц.», «гади», «хатын-кыз теленнән» дигән билгеләр куеп барган.

Сүзлекнең күләмле булуының тагын бер сәбәбе – авторның икеләтелгән максаты. Бернчедән, бу фәнни сүзлек булса, икенчедән, ул студентлар өчен уку әсбабы ролен үтәгән. Чөнки сүзлектә әдәби ядкярләрдә урын алган сүзләр һәм тезмәләр теркәлгән.

Сүзлектәге сүзләр гарәп графикасында һәм гарәп алфавиты тәртибендә бирелгән. Ләкин һәр сүзнең рус хәрефләре белән транскрипциясе күрсәтелә.

Мәсәлән, *тос.* قاباق 1) затворъ, забор на межъ (чтобы чужой скотъ не ходелъ), 2) = قاباق ( с.2 ),

Бу, әлбәттә, тел өйрәнүченең эшен күпкә җиңеләйтә. Л. Будагов моның белән генә чикләнми, ул да, югарыда күрсәтелгән авторлар кебек, сүзләрнең килеп чыгышына игътибар итә, сүзләр янына аларның кайсы телдән керүләрен дә искәртеп үтә. Моның өчен махсус кыскартылмалардан файдалана: а.=арабское, алт. = алтайскаго, баш.=башкирскаго, бух.=бухарскаго, каз.=казанскаго, кир.= киргизскаго, п.=персидскаго, тур.=турецкое. Бу күренеш, безнең карашка, сүзлек белән эшләүне җиңеләйтә, сүзлекнең үз кыйммәтен тагын да арттыра. Л.З.Будаговның «Сравнительный словарь турецко-татарских наречий… » хезмәтендә китерелгән сүзләр гаять күп һәм алар төрле өлкәләргә карый. Сүзлектәге сүзләрне туганлык атамалары, ашамлык, үсемлек исемнәре, кием-салым, тукыма, савыт-саба, эш кораллары, предметлар, географик атамалар һ.с. тематик төркемнәргә берләштерергә була.

Сүзлекнең тагын бер мөһим ягы итеп анда теркәлгән мәкаль-әйтемнәрне күрсәтергә була. Алар арасында хәзер кулланылыштан төшеп калган мәкаль-әйтемнәр дә бар: *Җаман катын үлсә, түшәк җаңарыр, җакшы катын үлсә - баш каңгырыр* (каз. II т., с.19).

Югарыда әйтелгәннәргә нәтиҗә ясап, сүзлекнең түбәндәге мөһим үзенчәлекләрен билгеләргә кирәк: күп кенә сүзләр этимологик чыгышлары ягыннан аңлатыла (күп очракта бик уңышлы); терминнарда (административ, хокукый, фәнни, дини һ.с.) еш кына тиешле чыганак һәм әдәбиятка сылтамалар

белән кыскача аңлатмалар китерелә; географик атамалар, төрки эпос һәм фольклор геройлары исемлеге, тормыш чынбарлыклары һәм төрки халыкларның гореф-гадәтләрен белдергән кайбер сүзләр кагыйдә буларак кыскача аңлатмалар белән тәэмин ителгән. Бу мәгълүматлар сүзлекне аңлатмалы, этимологик һәм өлешчә энциклопедик сүзлекләргә хас әһәмиятле үзенчәлекләр белән бик баеталар. Шушы чыганакларга нигезләнгән Л.З. Будагов сүзлеге борынгы төрки әдәбиятны һәм тарихи әсәрләрне укыганда бик яхшы ярдәмче була ала.

XIX гасыр ахырында миссионерлар җәмгыяте тарафыннан христиан динен пропагандалаган китаплар бастырыла. Рус булмаган халыкларга христиан дине тәгълиматларын өйрәтү шул халыкның милли телен яхшы белүне таләп итә. Шул максаттан христиан миссионерлары төрле телләрне, шул исәптән татар телен дә бик җентекләп өйрәнәләр. Җәмгыять ике телле сүзлекләр бастырып чыгара башлый. Шушы басмалар арасында Н.Остроумовның 1876 нчы елда чыккан «Первый опыт словаря Остроумова народно-татарского языка по выговору крещеных татар Казанской губернии», һәм 1892 нче елда дөнья күргән «Татарско-русский словарь» дигән хезмәтләре бар.

Н.Остроумов - йөзләгән басма хезмәтләр авторы. Алар арасында **«Первый опыт словаря Н.Остроумова народно-татарского языка по выговору крещеных татар Казанской губернии»** (1876) һәм **«Татарско-русский словарь»** (1892) аеруча игътибарга лаек.

Беренче сүзлек (1876) Казан император университеты типографиясендә басылган һәм керәшен мәктәпләре өчен файдалы кулланма итеп тәкъдим ителә. Бу сүзлек 145 биттән гыйбарәт. Кереш өлешендә татар теленең тарихы, грамматикасы, фонетика һәм морфологиясе турында тулы мәгълүмат бирелә.

Н.Остроумовның 1892 нче елда чыккан «Татарско-русский словарь»ын миссионерлар җәмгыяте сүзлеге дип йөрткәннәр. Сүзлек өч кеше: Н.Ильминский, Н.Остроумов һәм А.Воскресенский тарафыннан төзегән. Ләкин беренче булып бу эшне Н.Остроумов башлый. Ул сүзләрне туплый, терки, ә Н.Ильминский сүзлекне бастыра, А.Воскресенский Н.Ильминскийның ярдәмчесе була һәм аның эшен дәвам итә. Бу хезмәт 244 биттән гыйбарәт, барлыгы 1710 сүзне берләштерә.

Н.П. Остроумовның һәр сүзлегенә аерым тукталып үтик. 1876 нчы елда дөнья күргән сүзлек лексик яктан бик бай. 1892 елда чыккан сүзлектән аермалы буларак, монда искергән, диалектларда гына сакланган, яисә бөтенләй сөйләм теленнән төшеп калган сүзләр күбрәк урын алган. Алда каралган сүзлекләрдән аермалы буларак, Н.Остроумов хезмәтләре бары тик кирилл графикасында гына язылган, ә сүзләр рус алфавиты тәртибендә урнаштырылган. Н.Остроумов бу сүзлекләрне төзегәндә төп максат итеп сүзлекләр ярдәмендә татар халкын христиан дине

белән таныштыруны куя. Бу сүзлекләр миссионерлык максатларын тормышка ашыру һәм миссионерлар мәнфәгатен яктырту белән беррәттән, рус халкына татар телен өйрәтүдә зур эш башкаралар. Бу сүзлекләр чыгуда, миссионерләр теләгеннән тыш, җәмгыяви ихтыяҗ да төп урынны алып тора.

Н.Остроумовның 1876 нчы елда чыккан хезмәте «сүзлек» дип аталса да, ул үз эченә татар халкы тарихы, татар теле, мөселманнар, миссионерлар турындагы бай материалны ала. Моннан кала, Н.Остроумов сүзләрне фонетик, морфологик яктан яктан анализларга тырыша. Авазлар күчешен, авазларның бер-берсенә ничек тәэсир итүен, иренләшү-иренләшмәү, аваз өстәлү, кыскартулар үрнәкләрен ачык мисаллар белән күрсә. Мәсәлән: *сапля* - цапля (б. 21), бу – *быу* (б.61), китер – *килтер* (б. 90) һ.с.

Морфологик яктан тикшергәндә Н.Остроумов күбрәк фигыльләргә игътибар итә. Ләкин фигыльләрне теркәүдә бертөрлелек сакланмый. Мәсәлән: *булмыш* (б.61), *әйтештер* (б. 58).

Н.Остроумовның 1892 нче елгы сүзлегенең төзелешенә килгәндә, хезмәтнең кереш өлеше бик кыска язылган. Анда бары тик татар хәрефләренең язылыш тәртибе һәм тыныш билгеләре турында гына берникадәр мәгълүмат бирелгән. Ләкин төп өлеше, ягъни сүзлек - лексиканың байлыгы, сөйләшләрнең төрлелеге, искергән сүзләрнең, гарәп-фарсы алынмаларының аз булуы белән аерылып тора.

Н.Остроумовның 1892 нче елда дөнья күргән хезмәтендә түбәндәге аңлатма бирелә:

I. а) сүзләрдә рус хәрефләренең кулланылышы;
   б) басым;
   в) татар сүзләренең әйтелеше.
II. Татар теленең этимологиясе:
   а) сузыкларның яңгыраш закончалыгы;
   б) тартыкларның яңгыраш закончалыгы;
   в) кушымчалар;
   г) исемнәр, сыйфатларның һ.с. зат, сан, заман белән төрләнеше;
   д) фигыльләрнең килеш белән төрләнеше;
   е) фигыль – сүз төркеме буларак;
   ж) җөмләдә сүзләр кулланылышы.
III. а) Рус хәрефләренең тәртибе;
   б) русча-татарча сүзлек;
   в) туганлык терминнары таблицасы.

Н.Остроумов, сүзлекләрендә диалекталь, искергән, алынма сүзләр дә бар. Алар арасында иң зур урынны керәшен сөйләшләренә хас диалекталь лексика тәшкил итә. Диалекталь лексика проблемасы – искиткеч кызыклы, мавыктыргыч

һәм тарихи яктан бик мөһим мәсьәлә. Бу мәсьәлә үзенә аерым игътибар итүне сорый.

Н.Остроумов сүзлеге алдагы сүзлекләрдән гадилеге, җиңеллеге белән аерылып тора. Сүзлек, нигездә, халыкның җанлы сөйләменә нигезләнә. Шул сәбәпле, сүзлектә диалекталь берәмлекләр шактый зур урын алып тора.

Татар теленең бай тарихи язма әдәбиятында сүзләрнең искергән мәгънәләрен күп табарга мөмкин. Безнең телебездә югалган мәгънәләр кайбер башка төрки телләрдә яисә диалектларда, сөйләшләрдә яши. Н.Остроумов сүзлекләреннән иллегә якын искергән лексик берәмлекләрне аерып тикшердек. Бу сүзләр иҗтимагый - тарихи шартларның үзгәрүе-үсүе нәтиҗәсендә актив кулланылыштан төшеп калганнар һәм шул чорга караган сүзлекләрдә генә теркәлгәннәр.

«К. Насыйриның **«Татарча-русча лөгать китабы»** 1859 нчы елда ук төзелә башлый. Ләкин басылып чыгуы ни өчендер соңарган» (В. Хангилдин, 1948: 80 ). Бу сүзлекнең дөнья күрүендә китап сәүдәсе белән шөгыльләнүче Фәтхулла Хәмидулла улы Амашевның ярдәме зур була. Китап 1878 нче елда басылып чыга. Сүзлек, иң беренче чиратта, ике максатны күз уңында тота: ул татарларга рус теле, русларга татар телен өйрәтүдә куллану өчен әһәмиятле гамәли кулланма хезмәтен үти. Күләме — 120 бит, Һәм ул үз эченә 2923 сүз ала. Хәзерге чорда галимнәр һәм укытучы – практиклар әйтүенчә, 1500-3000 сүз теге яки бу телдә иркен аралашу өчен җитәрлек лексик база булып санала. К. Насыйри, үзенең укыту тәҗрибәсеннән чыгып, әлеге фикерне инде 120 ел элек дәлилләгән була. «Татарча-русча лөгать»нең керешендә К. Насыйри татар Һәм рус телләре фонетикасы турында кыскача мәгълүмат бирә. Кереш өлештә «Рус азбукасында хәрәкәткә йөри торган хәрефләр», «Слоглар», «Ударение бәянында» дигән бүлекләр булу шул турыда сөйли. «Урысның берничә төрле гласный хәрефләре өчен бары үземезнең шул өч хәрефемезне истигъмаль кылмак кирәк, әмма бу мөмкин түгел", – ди К. Насыйри. Рус телендә хәрефләрнең ике төрле, ягъни баш (зур) һәм юл (вак) хәрефләре булуын, сулдан-уңга язылуын да искәртеп үтә. Бу ике телдә иҗек һәм басымның уртак Һәм үзенчәлекле якларын билгели. Басымның татар телендә, гадәттә, сүз ахырында, ә рус телендә төрле иҗектә килә алуын Һәм басымга карап мәгънә үзгәрүен ассызыклый: «Аларның бәгъзе кәлимәләре бар, бер рәвешле языла, әмма ударениесенә карап, мәгънәгә дәләләт кыйладыр. Мондаен хосусларда алар ударение галәмәтен куймакны зарур күрәләр. Мәсәлән: *газаб* – мука, *он* – мука». Керешнең соңгы өлешендә «Урыс хәрефләренең кайсы хәрефләр бәрабәренә әйтелүе» дип, алфавит тәкъдим ителә. Автор укучыга сүзлекнең кереш өлеше белән танышырга һәм анда әйтелгән фикерләргә игътибар итәргә кирәклеген искәртә: «Бу лөгать китабындан бер файда хасил итим дигән адәм ошбу безнең язылмыш мөкаддимәмезне мөтәләга кыйлып (укып), үз галәмәтләренең вадигын (куелышын) белсеннәр» (Насыри, 1878:3). Күргәнебезчә,

галим тарафыннан бик акыллы һәм үтемле кереш сүз язылган. Ул татар телен өйрәнергә теләүчеләргә бик файдалы методик ярдәм хезмәтен үти.

Бу сүзлек үзенең төзелеш принциплары белән хәзерге сүзлекләргә бик якын. Анда сүзләр алфавит тәртибендә урнаштырылган. Сүзләр дүрт баганага бүленеп бирелә: беренче баганада гарәп алфавиты тәртибендә, гарәп графикасында татарча сүз бирелә; икенчесендә — сүзнең рус хәрефләре белән транслитерациясе, ягъни рус хәрефләре белән язылган татар сүзе; өченче баганада – сүзнең русчага тәрҗемәсе; дүртенче баганада рус сүзе гарәп хәрефләре белән бирелә. Бу алым XIX гасырда киң кулланылышта була. Бу чорда дөнья күргән татар теле үзөйрәткечләрендә дә чагылыш таба. Монда галимнәр тел өйрәнүчеләр өчен ике телнең фонетик мөмкинлекләрен, әйтелеш һәм язылыш үзенчәлекләрен бирергә тырышканнар. Әлбәттә, бу алым телне җиңелрәк үзләштерергә ярдәм иткән.

К. Насыйриның 1892 елда дөнья күргән русча-татарча сүзлеге XIX гасырның икенче яртысында төзелгән сүзлекләр арасында аеруча күренекле лексикографик хезмәтләрдән санала. Сүзлекнең тулы атамасы – «**Полный русско-татарский словарь с дополнением из иностранных слов, употребляемых в русском языке как термины**». Ул 264 биттән гыйбарәт һәм иң күләмле сүзлекләрнең берсе буларак билгеле.

«К. Насыйри бу сүзлекне турыдан-туры татарларга рус теле өйрәтү өчен белешмәлек, кулланма итеп төзегән» (В. Хангилдин, 1948:82). «Русча өйрәнүчеләргә бераз нәсыйхәт" исемле кереш сүзендә автор бу хезмәтенең 35 еллык эш тәҗрибәсе икәнлеген әйтә, «бу вакытка кадәр бездә тел өйрәнү юк иде», – ди. Рус телен өйрәнүгә карата киңәшләр бирә, дүрт таләпне шарт итеп куя. 1) Аерым сүзләрне белү. Аларны, җиләк җыйганда үзең дә сизмәстән чиләк тутырган шикелле, әкрен-әкрен үзләштерү. 2) Авазларның әйтелешен белү. 3) Өйрәнелә торган телнең морфология һәм синтаксисын белү. «Телне конвертларда адрес язу өчен генә өйрәнергә ярамый, чөнки мондый максаттан чыгып өйрәнүчеләр бервакытта да теләкләренә ирешә алмыйлар», – ди К. Насыйри һәм телне өйрәнүнең чагыштырма метод базасына корылган булырга тиешлеген дә әйтеп уза. 4) Рус префиксларының үзенчәлекләрен исәпкә алу (Насыри, 1892:3-5). Автор тарафыннан бирелгән бу тәкъдим-киңәшләр бүгенге көн өчен дә актуаль яңгырый.

Сүзлеккә шул чор рус әдәби телендә кулланылган рус сүзләре, шулай ук алынмалар теркәлгән. Бу турыда автор үзе хезмәтенең титул битендә әйтә: «Рус кәлимәләренең мәгънәсе тәфсыйлән бәян кылынып, хәрфе җәрле (предлог, приставкалы) фигыльләр дә, вә дәхи һәрбер хәрфе җәрнең мәүзугы ләһ (үзенә хас) мәгънәләре дә тәфсыйлән бәян кылынды. Янә рус кәлимәләреннән башка рус телендә мөстәгъмәл булучы әҗнәби лөгатьләр (чит тел сүзләре), рус телендәге

фөнүне шәтта истыйлахлары (төрле фәннәргә караган атамалар) – күбрәк чит тел сүзләредер, зикер кылынды».

Сүзлекнең төзелеш методикасына килгәндә, автор үз хезмәтендә төрле алымнарнеы куллана. Сүзләрне тәрҗемә иткәндә туры тәрҗемә, синонимнар белән тәрҗемә итү һәм аңлату юлы белән сүзләргә шәрехләү алымы киң кулланылган. Кайбер урыннарда сүзлек аңлатмалы сүзлеккә охшап китә. Әлбәттә, сүзләрнең эквивалент тәрҗемәсенә меңләгән мисаллар китерергә мөмкин, мәсәлән, аистъ – له لك لقلق (с. 5), барсъ - قبلاق (с.7) һ.б.

Күп очракларда эквивалент тәрҗемә белән синонимнар белән тәрҗемә алымы килеп керә. Синонимик рәттә татар сүзләре белән бергә гарәп-фарсы алынмалары да теркәлеп бара. Моңа мисал итеп түбәндәге сүзләрне күрсәтә алабыз: армия – لشكر عسكر(с. 6), арбузъ – بطيخ خفر خربو زه قار بو ز (с. 6)

Аңлату юлы белән бирелгән берәмлекләр сүзлеккә теркәлгән рус я европа сүзләрен татар укучысына тирәнтен аңлау мөмкинлеген бирә. Мәсәлән, аллея – اعاج ارا سنداعي يءللار(с. 5), ампутация - ادمنهرنك بر اعضاسى كيسوب الؤ (с. 5), глазурь – تاش صاوث وحولماق كبك نهرسه كرننك طشندا بىا لا سيمان نرسهدر (с. 30), акробатъ –ارقان اوستونده اوينا و جى (с. 5), актер – ثماشا حانه ده اوينا وحي (с. 5)

Үзенчәлекле терминнар, татар теле өчен чит атамалар гарәп-фарсы алынмалары я аңлату юлы белән тәрҗемә ителәләр. Кайбер очракларда ике Юл бергә кушыла. Мәсәлән, атом – ذرب جزئ لا يثجزي, барбарис عببر نار يس بر باريس, архитекторمهندس معمر

«Русча-татарча» сүзлеккә 18 меңгә якын берәмлек алынган. Лөгатьлектә сүзләр рус алфавиты тәртибендә урнаштырылып, шул чор орфографиясе буенча язылган. Тәрҗемә өлешендәге сүзләр гарәп графикасында бирелгән. Китапның соңгы битендә һәр хәреф буенча сүзләрнең башланган бит санын күрсәткән таблица урнаштырылган. Шулай итеп, К. Насыйри сүзлекнең техник төзелешен дә заманындагы алдынгы үрнәкләр нигезендә, рус сүзлекләре төзелеше кебек формалаштырган.

«Русча-татарча сүзлек»нең ахырында К. Насыйри «Әлфаз әҗнәбия», ягъни "Чит сүзләр" дигән баш астында рус теленә башка телләрдән кергән сүзләр Һәм терминнар сүзлекчәсе урнаштыра. Биредә артиллерия, антропология, барометр кебек 1700 гә якын иҗтимагый-сәяси, фәнни-техник терминнар урын ала. Рус телендәге бу алынмаларга татар телендә аңлатмалар бирү, тәрҗемә итү сүзлекнең кыйммәтен тагын да арттыра Һәм бу күренеш үз чоры өчен зур яңалык булып тора.

XIX гасырда төрки халыкларның телләрен, фольклорын һәм этнографиясен өйрәнүдә православ миссионерлар зур роль уйнаганнар. Христиан рухани уку йортларының татар теле укытучылары да әлеге хәрәкәт тарафдарлары

булганнар. Алар камил татар теле дип керәшен сөйләшләрен санаганнар һәм шул шивәләрдә дәрес биргәннәр, татар телен шул җирлектә өйрәткәннәр.

Православ миссионерлар татар лексикографиясе өлкәсендә дә зур эз калдырганнар. Миссионерлар җәмгыяте төзегән «**Краткий татарско – русский словарь с прибавлением некоторых славянских слов с татарским переводом**» сүзлеге биш тапкыр басылып чыга (Казань, 1880. – 55 с.; 1882. – 55 с.; 1886. – 96 с.; 1888. – 96 с.; 1891. – 96 с.), ләкин алар өйрәнелмәгән, теркәлгән лексик берәмлекләр тикшерелмәгән.

Сүзлекнең ике басмасы М.А.Гладышева, 1886 елда чыкканы М.А.Чиркова типографиясендә басыла, ә соңгы ике басманың типографиясе күрсәтелми.

Алда әйтелгәнчә, сүзлекнең биш басмасы дөнья күрә. Аларның форматы - 10 х 17,5, структур яктан тематик принципка нигезләнеп төзелгән. Өч басма бер – берсеннән аерылмый, дүртенче, бишенче басмаларның күләме зуррак. Авторлар соңгы басмаларга яңа сүзләр, яңа тематик төркемнәр, гарамматик материал өстиләр.

«Краткiй татарско – русскiй словарь съ прибавленiемъ некоторыхъ славянскихъ словъ съ татарскимъ переводомъ» дип аталган сүзлеккә киңрәк тукталырбыз, анда теркәлгән сүзләргә лингвистик күзәтү ясарбыз.

Сүзлек Казанда М.А.Гладышева типографиясендә 1880 елда басылып чыга. 55 биттән тора. Сүзлек тематик принципка нигезләнеп төзелгән. Барлыгы 43 төркем бар. Анда 983 сүз теркәлгән.

Төркемнәрнең исемнәре татарча һәм русча бирелгән: *ишек* алдындагы каралдылар – строенiя на дворе, ашамлыклар – съедобное, жорт кошлары – домашнiя прицы, сугыш кораллары – оружiя, кейемняр – одежды, агач атлары – названiя деревьевъ, донья жаклары – страны света, багыт – время, акча исабе – денежный счетъ, улчяуляр – весы, буйга улчяу – меры протяженiя, сыйык нястяне улчяу – меры жидкости, ой – домъ, ой эчендяге настяляр – вещи въ доме, жимешляр – плоды, гомбяляр–грибы, куренмей торган нястяляр – предметы отвлеченные, уйынчыклар – игрушки, чиркяу айберляре – церковныя вещи, укыту нястяляре – учебныя вещи, тешлей торган ыуак жяннекляр – насекомыя, кейекляр – звери, жирянгеч жяннекляр – гады, жорт терлекларе – домашнiя животныя, эчемнекляр – напитки, кеше тяненен саннары – состав человеческаго тела, ындырдагы нястяляр – вещи на гумне, кыр кошлары – дикiя птица, урман кошлары – лесныя птица, ауадагы нястяляр – предметы небесные, бакча – огородъ, мунча – баня, жир – земля, тосляр – цвета, балчык эчендяге нярсяляр – металлы, ташлар – камни, нястянен ничеклеге – качества, ден сюзляре – слова веры, балта остасынын кораллары – плотничьи инструменты, тимерче – кузнецъ, ашлыклар – хлеба, улямняр – растенiя, кыйлану сюзляре – глаголы. Сүзләрнең язылышы нәкъ сүзлектәгечә бирелде. Бу сүзлекләрне төзүчеләр

Казан университеты профессоры миссионер Николай Ильминский алфавитын кулланып эш иткәннәр.

Сүзлектә төрле сөйләшләргә хас булган диалекталь берәмлекләр дә бар, ләкин алар күп түгел: *бистяр – полотенце* (с.6), *туйра – дубнякъ* (с.7) *эт бороно – шиповникъ* (с.8) һ.б..

Сүзлектә урын алган лексик берәмлекләр арасында рус алынмалары шактый күп. Аларның күбесе татар теленең фонетик закончалыкларына буйсынган, телдә эквиваленты булмаган берәмлекләр. Мәсәлән, *клят – клеть* (с.3), *прянник – пряник* ( с.4), *эштей – щи* (с.4) һ.б.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, бу сүзлек тел өйрәнүчеләр өчен бик уңайлы булган. Чөнки авторлар икенче телгә өйрәтүнең бөтен нечкәлекләрен белеп эш иткәннәр. Көндәлек аралашу өчен кирәкле иң актив берәмлекләрне генә туплану, аларны тематик төркемнәргә аерып бирү, телгә хас фонетик закончалыкларын язуда чагылдырырга тырышу, тәрҗемә иткәндә, нигездә, эквивалентлар белән эшләү аларның тәҗрибәле, оста лексикограф булулары турында сөйли.

Ш. Рәхмәтуллин (Шиһабетдин Габделгазиз ) татарларны рус теленә өйрәтүгә дә үзеннән өлеш кертә. Ул сүзлекләр, үзөйрәткечләр авторы буларак та билгеле. Аның ике сүзлеге безгә мәгълүм.

Ш.Рәхмәтуллинның Ш.Габделгазиз исеме белән басылган **«Татар теленнән русчага һәм урыс теленнән татарчага тәрҗемә лөгать яки словарь»** дигән хезмәте 1893 елда Казан университеты табгыханәсендә басыла. Китап 15х23 см форматта, 72 битле. Сүзлекнең исеме русча да бирелгән: «Переводъ съ татарскаго на русскій языкъ или словарь». Исеменнән соң: «Бу тәрҗемәдә һәр затны җенесе вә нәүгысы илә аерым фасылларда бәян кылынгандыр, таки бер мәгълүм нәрсәнең исемени белмәк ирадә кылындыкта дәфгатән табу асан булсын өчен», дип куелган. 1892 елның 28 гыйнварында Санкт-Петербург цензурасы сүзлекне бастырып чыгарырга рөхсәт бирә. Сүзлекнең авторы Шиһабетдин Габделгазиз дип күрсәтелгән.

Сүзлек, алда әйтелгәнчә, аерым өлешләрдән тора. 40 бүлектә 1781 сүз тупланган. Тематик төркемнәр: «Адәм тәненең әгъзалары», «Кардәш – ыругларның исемнәре», «Кеше», «Киемнәр», «Ашамлыклар», «Үсемлекләр», «Хайваннар» һ. с.

Сүзләр гарәп һәм рус хәрефләре белән язылган. Битнең сулъяк яртысында татар сүзе, уң ягында рус сүзе гарәп һәм рус хәрефләре белән бирелгән.

Сүзлек ахырында «Җөмләләр һәм өзекләр» китерелгән. Бу җөмләләр гадидән катлаулана барып бирелгән. Алар арасында үгет – нәсыйхәт

характерындагы әйтемнәр, философларның сүзләре бар. Хезмәтнең ахырында мәкальләр тәрҗемә ителгән.

Сүзләр тематик төркемнәргә туплап бирелгән, алфавит тәртибе сакланмаган. Һәр тематик төркемдә мәгънәләре охшаш, тамырдаш сүзләр янәшә урнашкан.

Күләме ягыннан зур булмаган әлеге сүзлеккә бай лексик материал теркәлгән. Автор бары тик сөйләмдә актив кулланыла торган берәмлекләрне генә бирергә тырышкан. Сүзлек һәрьяктан да XIX гасырда дөнья күргән күпсанлы татар теле үзөйрәткечләренә бик якын. Бу ягы белән ул башка сүзлекләрдән аерылып тора.

Сүзләрне тематик төркемчәләргә бүлеп урнаштыру тел өйрәнүчеләрнең хезмәтен күпкә ансатлаштырган. Сүз төркемнәренә игътибар итү, аларга хас грамматик категорияләрне мисалларда гына күрсәтү Ш. Габделгазизнең чит тел өйрәтү методикасын яхшы белүе турында сөйли.

1894 нче елда «**Русско-татарский словарь»**ын бастырып чыгара. Сүзлек 374 биттән тора. Кереш сүз юк. Бары тик рус хәрефләренең урнашу тәртибе, ягъни рус алфавиты гына күрсәтелә. А.Воскресенскийның русча-татарча сүзлеге керәшен – татар мәктәпләрендә кулланыла торган төрле пособиеләрдәге сүзләрдән һәм Казан губернасының керәшен авылларыннан җыеп кайткан сүзләрдән төзелә.

А.Воскресенский сүзлеге искиткеч тулы, төгәл итеп эшләнгән. Автор рус сүзләренең татар телендәге эквивалентларын табарга тырыша. Даими рәвештә булмаса да, сүзләрнең кулланалыш даирәсен күрсәтеп китә. Мәсәлән: *Агнецъ* (ц.сл.) *бярян, Алла бяряне. Агнецъ непорочненный монсоз бярян, пасха бяряне* (с. 1), *бабка (игральная кость) кузна* (с. 3).

А.Воскресенский сүзләрнең тәрҗемәләрен бирү белән генә чикләнми, күп очракта ул сүзнең куллану мөмкинлекләрен күрсәтә, сүзтезмәләр составында сүзнең урынын билгели: *деньги - акча* (*вообще*), тянкя (*серебряныя*, которыя назыв. Также и комош акча). *Бумажныя* деньги кагаз акча. *Золотыя* деньги алтын акча. *Деньжонки* акча-мокча, акча асяре. За деньги продать акчага сат (с. 53).

Сүзлекнең тагын бер үзенчәлекле ягы – сүзләргә аңлатма биреп тәрҗемә итү: *касса – касса* (акча сала торган төш) (с. 101), *налогъ - налогъ* (айбер очен казнага тюляу) (с. 143), *профессоръ - профессоръ* (Академия белян Университетта ойрятеуче) (с. 259), *вакса- вакса* (итек чистарта торган нястя) (с. 17). Мисаллардан күренгәнчә, бу ысул татар телендә рус сүзләренә туры килә торган эквивалент булмаган очракларда кулланыла.

А.Воскресенский сүзлеген үзенең сүзлек составы ягыннан Н.Остроумов сүзлекләренә бик якын. Бу уртаклыкны автор үзе дә күрсәтә, чөнки аларның

максатлары, бурычлары бер була. Ләкин сүзлекләр беренче телләре белән аерылалар. Н.Остоумов сүзлекләре татарча-русча итеп төзелгән булса, А.Воскресенский беренче тел итеп рус телен ала. Аңлатма бирү алымнары ике сүзлектә дә бер типта эшләнгән, сүзләрнең бирелү рәвеше дә бер үк төрле, тәрҗемә ителергә тиешле берәмлек калын хәрефләр белән тәкъдим ителә.

1894 елда Казан Император Университеты типографиясендә Е. Неклюдовның «**Словарь – самоучитель 1500 татарских слов**» хезмәте басылып чыга. Бу кулланма татар телен үзлегеннән өйрәнүчеләргә адресланган. Автор аны бигрәк тә Себер төбәгендә яшәүчеләр өчен дип ассызыклый. Сүзлек- үзөйрәткечкә 1500 сүз теркәлгән. Алар рус алфавиты тәртибендә урнаштырылган. Сүзләр башта русча бирелә, татар теленә тәрҗемә ителә һәм гарәп гафикасына транслитераөця ясала:

*Бог – Алла, Тәңре, Худай*
*Бровь – каш*
*Бабушка – эбий, улкун ана* (с.8)

Кулланма кесә сүзлеге форматында төзелгән. Автор аны Себер җирлегендә сәүдә эшләрендә ярдәмче булсын дип эшли. Татар теленең төрки халыклар белән аралашуда кирәклеген сүзлекнең кереш мәкаләсендә аңлатып китә.

Хезмәтнеә ахырында, кушемта формасында, һинд саннары таблицасы бирелә. Бу саннар рус һәм татар теленә тәрҗемә итеи күрсәтелә.

К.Насыйри 1894 елда «**Гөлзар вә чәмәнзар**»га аерым сүзлек китабы бастыра.Биредә 313 үсемлекнең русча, татарча атамалары күрсәтелгән. Безнең төбәктә үскән 192 дару үләненә аңлатма бирелә.

Китап Октябрь революциясенә кадәр татар халкы арасында бик популяр була. Аның 1903 елда кабаттан басылуы да шуны дәлилли.

Бу хезмәттә ботаника һәм медицинага караган күптөрле терминнар урын алган. Төп терминнарның татарча, русча һәм латинча китерелә:

*Гөлбәдран –рябинка –tanacetum* (23);
*Үги ана яфрагы – мать и мачеха – tussitago* (22);
*Тимер үлән – железняк аптечный – verda officinalis* (27);
*Мәтрүшкә – душица обыкновенная – origanum vulgare* (26) һ.б.

Кайбер очракларда үләннәрнең гарәпчә исемнәре дә күрсәтелә: ишәк *колагы – живокость аптечный – symphutum officinale - әзән әл-химар*, гарәпчә (31), *бөтнек үләне – мята – mentha - нәгнәг* (31) һ.б.

Кайчакта төп термин гарәпчә бирелеп, аңа татарча адекватлар китерелә: гаттас – гатәсә үләне, ягъни төчкерек уты (22) һ.б.

Татар телендә әзер исемнәре булмаган төшенчәләрне биргәндә К.Насыйри тәрҗемә методы һәм калькалаштыру алымнарыннан файдалана: *ангелика – фәрештә уты* (29), *ааронова борода – һарун сакалы* (57), *меңъяфрак – тысячилистник* (21), *красавица маргаритка – гүзәл гаурәт* (55) һ.б.

Каюм Насыйриның «Гөлзар вә чәмәнзар» хезмәтендә рус алынмалары да чагылыш таба. Бу берәмлекләр арасында мендаль, керән, кәбестә кебек берәмлекләр бар.

Китапның ахырында үләннәрнең гарәпчә-татарча исемлеге теркәлгән, нинди авырулардан кулланылуы турында мәгълүмат бирелгән.

Каюм Насыриның **«Ләһҗәи татари»** сүзлеге - ике томлык хезмәт. Беренче томы – 1895, ә икенче томы 1896 нчы елларда Казан университеты типо-литографиясендә басылган. Беренче өлеше «ا» (әлиф), «ص» (сад) хәрефләрен үз эченә алып – 226, икенче өлеше «ض» (зад), «ی » (йай) хәрефләрен үз эченә алып 107 биттән тора. Сүзлеккә ун мең ярым чамасы лексик берәмлек беркетелгән. Алар арасында сүзтезмәләр һәм фразеологик берәмлектәр дә бар. Автор аларга семантик-грамматик һәм этимологик аңлатмалар бирелә. Генетик яктан караганда, төп өлешне төрки-татар сүзләре тәшкил итә, гарәп-фарсы алынмалары да сүзлектә теркәлгән. Сүзлек үзенә язма һәм сөйләм теленә тел хас үрнәкләрен берләштерә, шул чорда киң кулланылышта булган тел байлыгын чагылдыра.

«Ләһҗаи татари» да сүзләрнең мәгънәләре төрле юллар белән аңлатыла. Монда сүзләрнең синонимнарын бирү, күпмәгънәлекне күрсәтү – барысы да кулланыла.

Сүзләр гарәп алфавиты тәртибендә 33 хәреф астына урнаштырылган. Сүзлектә һәр сүз аерым мәкалә итеп формалаштырылган. К. Насыйри баштагы берничә хәрефкә аның исеме, нинди санга туры килүе, алфавиттагы урыны, яңгырашы турында белешмә бирә, ә калган хәрефләрнең нинди санга туры килүен генә күрсәтә.

«Ләһҗәи татари» да мөстәкыйль сүзләр дә, ярдәмлекләрдә чагылыш таба. Аларның лөгатьлеккә теркәлү тәртибе, нигездә, татар теленең өч томлык аңлатмалы сүзлеге кагыйдәләренә туры килә. Автор аерым лексик берәмлекләр итеп төрле аффикс һәм кисәкчәләрне дә лөгатьлеккә урнаштырган. Сүзлекләрнең күпчелегенә К.Насыйри грамматик характеристика бирә, ягъни кайсы сүз төркеменә караганлыгын, грамматик мәгънәсен искәртеп бара. Бу – хәзерге көн сүзлекләр төзүдә кулланылган принцип.

Каюм Насыйриның «Ләһҗәи татари» сүзлеге татар лексикографиясендә беренче аңлатмалы сүзлек буларак зур кыйммәткә ия булган язма истәлек булып санала. Әлеге сүзлек турында җентекле анализ әлеге хезмәтнең 12 нче бүлекчәсендә бирелгәнлектән, биредә гомуми күзәтү белән чикләнәбез.

М.Юнусовның «**Татарско-русский словарь наиболее употребительных слов и выражений, составленный учителем русскаго класса при Чистопольскомъ городском медресе Юнусовым**» хезмәте 1900 елда Казанда «Кәримовлар»сәүдә йорты типографиясендә дөнья күрә. Хезмәт 115 бит тәшкил итә, 4848 сүздән тора, барлыгы 1000 данә басыла. Автор, нигездә, татар теленең иң актив сүзлек байлыгын чагылдырган. Мәсәлән, *аулъ – деревня* (с.5), *аксакъ – хромой* (с.7), *бить – лицо* (с.21), *бауръ – печень* (с.30), *бозъ – ледъ* (с.31). Моны хезмәттә урын алган тотрыклы сүзтезмәләр, фразеологик әйтелмәләрнең бирелүе дә раслап тора: *акылдан язмакъ – лишиться ума* (с.10), *акылданъ чыкмакъ – сойти съ ума* (с.10); *акылданъ таймакъ – съ ума спятиться* (с.10), *эрямъ тамакъ – дармоедъ* (с.19), *эч поша – сердце ноетъ* (с.20), *джиль куаръ – ветрогонъ* (с. 58).

Сүзлеклер төзелеше - гади дә, уңышлы да.

Сүзлек коммуникатив максатларны күздә тотып төзелгән. Шуңа күрә дә автор беренче урында дөрес язуга түгел, дөрес ◎әйтүгә игътибар юнәлтә. Шура күр◎ кирилл алфавитында, татар сүзләрен укыганда кыенлыклар тумасын өчен, автор «ПРИМЕЧАНИЕ» дә◎ куя:

«*Дж* соответствует татарской буквъ ج и означаетъ звукъ между ж и *ч*, лапр. въ словъ *джиханъ – міръ;* Н соотвътствует татарск. نك и озлачаетъ носовой звукъ *нг*, лапр. въ словъ *танъ – свътъ;* Надстрочный знакъ двъ точки служитъ для смягченія гласлых *у* и *о* » һ. с. (с.3)

Сүзлектә фигыльл◎р -мак/-мәк формасында һәм исем фигыльләр -у/-ү формалары белән тәкъбир ителәләр: *элекляу – сплетничание* (с.16), *ачмакъ – открыть, открывать* (с.10)

М.Юнусов сүзлегенең башка сүзлекләрдән тагын бер аермалы ягы - басымга игътибар итү. Автор һәр сүзнең басымын куеп бара, бу күренеш татар сүзләрене белән чикләнмичә, рус сүзләрендә дә чагылыш таба.

Хезмәттә◎ тормышның төрле өлк◎сен◎ караган диалекталь сүзл◎р дә чагылыш таба. М.Юнысов үзе яшәгән Чистай, Бошкортстан төбәкләрендәге ◎җирле сөйләм үзенчәлекләренә◎ күбрәк басым ясый.

Шунысы кызыклы: сүзлектә телдә◎ еш кулланыла торган, аралашу өчен иң кирәкле сүзтезмәләрне дә◎ очратып була. *Ат белән бармакъ – ехать на лошади* (с.12), *ат блян юрмякъ – ездить на лошади* (с.12), *башмакъларны кимякъ – одъвать башмаки* (с.26), *кайнаръ су – кипятокъ* (75). Билгеле, автор бу сүзтезмәләрне татар телен үзләштерүне ◎җиңеләйтү һәм тизләтү максаты белән кертә.

М.Юнысовның бу сүзлеге үзенең гади, аңлаешлы булуы белән аерылып тора. Ул турыдан – туры татар теле өйрәнүчеләргә атап язылган. М.Юнысов башка милләт вәкилләренә тел өйрәтү методикасын яхшы белгән. Бу авторның сүз сайлау алымында да чагыла, чөнки сүзлеккә актив лексика гына тупланган. Рус

теленнән кергән сүзләр, гарәп фарсы алынмалары башка сүзлекләргә караганда чагыштырмача аз.

Автор бер генә алфавиттан файдаланган. Ләкин алфавит төгәл, системалы рәвештә сакланмый. Кайбер урыннарда төгәлсезлекләр, сүзләрнең урнашу тәртибе бозылу күзәтелә.

* * *

XIX гасырда дөнья күргән татарча-русча һәм русча-татарча сүзлекләр арасында төрле максатларда чыгып төзелгән, төрле күләмле сүзлекләр бар. Кайбер сүзлекләр уку әсбапларына ярдәмлек, тел өйрәнүчеләргә кулланма итеп төзелгән булсалар, икенчеләре зур күләмле энциклопедик характердагы ике телле сүзлекләр булып торалар. Сүзлекләр, нигездә, әдәби тел материалына таянып төзелгәннәр, ләкин шул ук вакытта татар теленең төрле сөйләшләренә нигезләнгән, диалектологик сүзлек дип аталырлык хезмәтләр дә бар.

Гомумән алганда, XIX гасырда дөнья күргән татарча-русча һәм русча-татарча сүзлекләр телебезнең бер гасырлык лексик мирасын туплаган бик кыйммәтле хәзинә булып торалар. Аларны өйрәнү, сүзлекләргә теркәлгән сүзләрне лингвистик яктан тикшерү, сүзлекләр ярдәмендә телебезнең сүзлек составының бер гасырлык үсешен, хәрәкәтен күзәтү татар теленең лексикология фәненә, тарихи лексикологиягә бик зур өлеш кертер дип уйлыйбыз.

**ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ**

HAKOV, V. H. (1994), *Tatar edebi tele tarihı,* Kazan: Kazan Universiteti.

HANGİLDİN, V. N. (1948), "Kayum Nasıri hem Tatar leksikografiyasi", *Kayum Nasıri: 1825-1845, Tuvuvına 120 yıl tuvuvga bagışlangan gıylmi sessiya mater: Mecmuga*, Kazan: Tatgosizdat, 78-91.

MİNNİGULOV, H. Y. (1982), *XIX. Yöz Tatar Hrestomatiyaleri.* Kazan: Kazan Universiteti.

NASIROVA, G. G. (2002), "Deyatelnost Kayuma Nasıri v oblasti tatarskogo yazıkoznaniya", Avtoreferat dis. Kandidata filologiçeskih nauk: 10.02.02, Kazan: Kazan Gos. Uni.

ÖNER, M.; KAYA, M. Y.; ÖZŞAHİN, M. (2010), "Lehçe-i Tatari'nin Söz Varlığı Üzerine Bir Deneme", *Uçenıe zapiski Tavriçeskogo natsionalnogo universiteta im. V. İ. Vernadskogo Seriya Filologiya. Sotsialnıe kommunikatsii,* Tom 23 (62), No 3, 9-19.

SABEROVA, G. G. (1996), *Nazvaniya rasteniy v tatarskom literaturnom yazıke.* Kazan: Fiker.

TUMAŞEVA, D. G. (1992), *Slovar dialektov sibirskih tatar,* Kazan: izd. Kazan Universiteta.